–**ачак, -әчәк** присоединяется после согласных: *таныш-ачак (познакомится), очраш-ачак (встретится), башлан-ачак (начнется),*

*тәмамлан-ачак (закончится), урнаш-ачак (расположится), бир-әчәк (даст), күр-әчәк (увидит).*

**–ячак, -ячәк** присоединяется после гласных: *телә-ячәк (захочет), оша-ячак (понравится), аша-ячак (будет кушать), эзлә-ячәк (будет искать), җырла-ячак (будет петь), уйна-ячак (будет играть), кара-ячак (будет смотреть), сөйлә-ячәк (будет рассказывать).*

Отрицательная форма образуется при помощи **–ма-ячак, -мә-ячәк**: *таныш-ма-ячак (не познакомится), телә-ячәк- (не встретится), башлан-ма-ячак (не начнется), телә-мә-ячәк, оша-ма-ячак (не понравится), аша-ма-ячак (не покушает), кара-ма-ячак (не посмотрит).*

Будущее определенное время указывает на такое действие, в совершении которого говорящий твердо уверен, поэтому это время также называют будущим категорическим.

**Спряжение будущего определенного времени глагола**
**Аффиксы лица и числа**

| число | лицо | личные аффиксы |
|---|---|---|
| един. | I *(мин)*<br>II *(син)*<br>III *(ул)* | *-мын, -мен*<br>*-сың, -сең*<br>∅ |
| множ. | I *(без)*<br>II *(сез)*<br>III *(алар)* | *-быз, -без*<br>*-сыз, -сез*<br>*-лар, -ләр* |

Примеры спряжения

| число | лицо | Утвердительная форма | | Отрицательная форма |
|---|---|---|---|---|
| | | после согласных | после гласных | |
| един. | I *(мин)*<br>II *(син)*<br>III *(ул)* | *таныш-ачак-мын*<br>*таныш-ачак-сың*<br>*таныш-ачак* | *телә-ячәк-мен*<br>*телә-ячәк-сең*<br>*телә-ячәк* | *очраш-ма-ячак-мын*<br>*очраш-ма-ячак-сың*<br>*очраш-ма-ячак* |
| множ. | I *(без)*<br>II *(сез)*<br>III *(алар)* | *таныш-ачак-быз*<br>*таныш-ачак-сыз*<br>*таныш-ачак-лар* | *телә-ячәк-без*<br>*телә-ячәк-сез*<br>*телә-ячәк-ләр* | *очраш-ма-ячак-быз*<br>*очраш-ма-ячак-сыз*<br>*очраш-ма-ячак-лар* |

ЗАДАНИЯ

***1. Просклоняйте следующие глаголы.***

Ашаячак, сатып алачак, пешерәчәк, бирәчәк, ясаячак, түләячәк.

***2. Образуйте отрицательную форму глаголов и просклоняйте их.***

Ашаячак, сатып алачак, пешерәчәк, бирәчәк, ясаячак, түләячәк.

***3. Допишите аффиксы. Переведите.***

Дусларыгыз ял йортында ике атна бул…мы? Мин, Казанга килгәч, танышларымда яшә… . Сезнең улыгыз кайсы институтта укы… ? Сез яңа туган балагызга нинди исем бир… ? Бу атнада мин икенче сменада эшлә… . Рөстәм хәзер безгә дөресен сөйлә… . Мин беләм, сез миңа начар киңәшләр бир… . Кунакларны вокзалда без каршыла… .

***4. Переведите.***

1. Завтра опять будет холодно. 2. Сначала поужинаем, потом пойдем смотреть город. 3. В понедельнтк они вам позвонят, а во вторник вы их встретите. 4. Они еще раз подумают и дадут ответ. 5. Об этом вам расскажет менеджер. 6. Я вас всех послушаю, а потом скажу свое мнение. 7. Работа так быстро не закончится. 8. Поезд не будет вас ждать, поторопитесь. 9. Он никому ничего не скажет. 10. Времени опять не хватит.

***5. Прочитайте текст. Переведите.***

Бүген югары җитештерүчәнлекне һәм дөнья базарында көндәш булырлык товарларны гади эшче, техник һәм инженер түгел, югары дәрәҗәдә әзерлекле һөнәр иясе гена бирә ала. Кадрлар әзерләгәндә һөнәрне дөрес сайлау, специальләшү төп мәсьәлә булып тора.

Белем — корал ул. Халык әйтмешли, «Корал кемнеке — заман шуныкы». Димәк, өзлексез белем бирү системасын төзергә, һөнәри белем бирүне тамырдан үзгәртеп корырга кирәк. Монда илебездәге хәлне генә түгел, бөтендөнья үсү тенденциясен дә исәпкә алу кирәк.

*Сүзлек*

| | |
|---|---|
| югары | высокий |
| җитештерүчәнлек | производительность |
| көндәш булырлык | способный конкурировать |
| югары дәрәҗәдә | в высшей степени |
| әзерлекле | подготовленный |
| һөнәр иясе | специалист, мастер |
| мәсьәлә | задача |
| корал | средство, орудие |
| әйтмешли | как говорит |
| өзлексез | непрерывный |
| үзгәртеп кор-у | перестроить |
| исәпкә ал-у | учитывать |

***6. Сделайте сообщение о своей будущей профессии.***

## 11. Икътисад һәм икътисадый хезмәттәшлек. Сәүдә – Экономика и экономическое сотрудничество. Торговля

| | |
|---|---|
| акча | деньги |
| сатучы | продавец |
| сатып алучы | покупатель |
| алыш—биреш | купля—продажа, торговля |
| базар | рынок |
| бәя | цена |
| бурыч | долг |
| вәкил | представитель |
| йомыш | поручение |
| керем | доход |
| кибет | магазин |
| көндәш | конкурент |
| җитештерүче | производитель |
| кулланучы | потребитель |
| милек | собственность |
| салым | налог |
| тәкъдим | предложение |
| фирма | фирма |
| хак | цена, стоимость |
| чыгым | расход |
| эшкуар | делец, деловой человек, бизнесмен |
| ярминкә | ярмарка |
| алыш-биреш итү | заниматся куплей-продажей, торговлей |
| базар икътисады | рыночная экономика |
| бурычка алу | брать в долг |
| дәүләт милке | государственная собственность |
| хосусый милек | частная собственность |
| керем-чыгымны исәпләү | считать расходы |
| сыйфат | качество |
| сәүдә операциясе | торговая операция |
| ташлама | скидка |
| тигез шартлар | равные условия |
| товарның сыйфаты | качество товара |
| тормыш дәрәҗәсе | уровень жизни |
| тышкы базар | внешний рынок |
| тышкы сәүдә | внешняя торговля |
| түләү балансы | платежный баланс |
| эчке базар | внутренний рынок |
| югары бәя | высокая цена |
| чит илдән товар кертү | импортировать |
| чит илгә товар сату | экспортировать |

| *Сәүдә* | *Торговля* |
|---|---|
| Моның хакы күпме? | Сколько это стоит? |
| Бу күпме тора? | Сколько это стоит? |
| Бу бик кыйммәт. | Это очен дорого. |
| Бу бик арзан. | Это очень дешево. |
| Сез ташламалар ясыйсызмы? | Вы скидки делаете? |
| Бу товрның сыйфаты бик яхшы (начар). | У этого товара очень хорошее (плохое) качество. |
| Сез ташлама ясасагыз, мин сатып алам. | Если вы сделаете скидку, я это куплю. |
| Безнең фирма … сата (сатып ала) | Наша фирма продает (покупает)… |
| - промышленность товарлары | - промышленные товары |
| - киң куллану товарлары | - потребительские товары |
| - компьютерлар | - компьютеры |
| - автомобильләр | - автомобили |
| - телевизорлар | - телевизоры |
| - суыткычлар | - холодильники |

**Послелоги и послеложные слова (Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр)**

**Послелоги** по своей функции соответствуют русским предлогам. Послелогами их называют потому, что они употребляются после того слова, к которому относятся. Послелоги могут быть выражены собственно послелогами и послеложными словами (чаще именами, выражающими пространственные и временные отношения), выполняющими функции послелогов. Также функцию послелогов выполняют падежные аффиксы. Послелоги употребляются с определенными падежными формами:

| **Падежи** | **Послелоги** | **Примеры** |
|---|---|---|
| основной, притяжательный | белән, кебек, шикелле, төсле, сыман, аркылы, аша, турында, хакында, хакта, өчен, сәбәпле, аркасында | *әти белән — с отцом, минем белән – со мной, әти кебек — как отец, синең кебек — как ты, ут шикелле — как огонь, кеше төсле – как человек, куян шикелле — как заяц, юл аркылы — через дорогу, елга аша — через реку, аның аркылы — через него, китап турында — о книге, галим хакында — об ученом, безнең хакта — о нас Ватан өчен — за Родину, сезнең өчен, авыру сәбәпле — из-за болезни, аның аркасында — из-за него* |
| направительный | таба, табан каршы, | *Министерствога таба — к Министерству, дулкынга каршы — против волн,* |

| | | |
|---|---|---|
| | караганда,<br>карамастан | *Казан Мәскәүгә караганда кечкенәрәк шәһәр — Казань меньше, чем Москва,*<br>*яңгырга карамастан — несмотря на дождь* |
| исходный | башка, бүтән, тыш,<br><br>бирле,<br>башлап,<br>соң,<br>элек | *эштән башка — кроме работы, хатыннан бүтән — кроме жены, китаптан тыш — кроме книги,*<br>*иртәдән бирле — с утра, кыштан башлап — с зимы,*<br>*сугыштан соң — после войны,*<br>*синнән элек — до тебя* |
| основной, притяжательный,направительный | чаклы, хәтле, тикле, кадәрле | *йодрык чаклы — велечиной с кулак, диңгез чаклы — большое, как море, тау хәтле — как гора, синең хәтле — как ты, урманга хәтле — до леса,*<br>*борчак кадәрле — велечиной с горошек* |

**Послеложные слова**

| Основа послеложных слов | Падежные формы послеложных слов и соответствующие им русские предлоги | Примеры употребления |
|---|---|---|
| өс (верх) | өстенә (на)<br>өстеннән (с)<br>өстендә (на) | *өстәл өстенә — на стол*<br>*өстәл өстеннән — со стола*<br>*өстәл өстендә — на столе* |
| ас (низ) | астына (под)<br>астыннан (из-под)<br>астында (под) | *өстәл астына — под стол*<br>*өстәл астыннан — из-под стола*<br>*өстәл астында — под столом* |
| як (сторона) | ягына<br>ягыннан<br>ягында | *урман ягына — по направлению к лесу*<br>*урман ягыннан — со стороны леса*<br>*урман ягында — там, где лес* |
| ян (бок) | янына (к)<br>яныннан (от)<br>янында (рядом) | *әни янына — к маме*<br>*әни яныннан — от мамы*<br>*әни янында — рядом с мамой* |
| чак (время) | чакка<br>чактан<br>чакта | *яшь чакка (кайтасы килә) — во времена молодости (хочется вернуться)*<br>*яшь чактан — со времен молодости*<br>*яшь чакта (күңелле иде) — во времена молодости (было весело)* |
| каршы (на встречу) | каршына (к)<br>каршыннан (перед)<br>каршында (перед) | *егет каршына — к парню*<br>*егет каршыннан (узды) — перед парнем (прошел)* |

| | | |
|---|---|---|
| | | *егет каршында (тора) — перед парнем (стоит)* |
| буй (вдоль) | буена (к)<br>буеннан (со стороны)<br>буенда (у) | *елга буена — к реке*<br>*елга буеннан — со стороны реки*<br>*елга буенда — у реки* |
| тирә (вокруг) | тирәсенә (к)<br>тирәсеннән (от)<br>тирәсендә (у) | *чишмә тирәсенә — к роднику*<br>*чишмә тирәсеннән — от родника*<br>*чишмә тирәсендә — у родника* |
| ара (промежуток) | арасына (к)<br>арасыннан (от)<br>арасында (среди) | *кеше арасына — к людям*<br>*кеше арасыннан — от людей*<br>*кеше арасында — среди людей* |
| эч (внутрь) | эченә (в)<br>эченнән (из)<br>эчендә (в) | *шкаф эченә — в шкаф*<br>*шкаф эченнән — из шкафа*<br>*шкаф эчендә — в шкафу* |
| урта (середина) | уртасына (на середину)<br>уртасыннан (по середине)<br>уртасында (в середине) | *диңгез уртасына — на середину моря*<br>*диңгез уртасыннан — по середине моря*<br>*диңгез уртасында — в середине моря* |

## Наиболее употребительные предлоги русского языка и соответствующие им формы в татарском языке

| **Предлоги** | Соответствующие формы в татарском языке | **Примеры** |
|---|---|---|
| на | белән<br>өстендә<br>-да, -дә, -та, -тә<br>-га, -гә, -ка, -кә | *Мин эшкә машина белән барам (Я на работу еду на машине)*<br>*Китап өстәл өстендә ята (Книга лежит на столе).*<br>*Китап өстәлдә ята (Книга лежит на столе).*<br>*Мин эшкә барам (Я еду на работу).* |
| в | эчендә<br>-да, -дә, -та, -тә<br>-га, -гә, -ка, -кә | *Шкаф эчендә кием бар (В шкафу есть одежда).*<br>*Шкафта кием бар (В шкафу есть одежда).*<br>*Киемне шкафка эл (Одежду повесь в шкаф).* |
| над | өстендә<br>-дан, -дән, -тан, -тән, -нан, -нән | *Өстәл өстендә картина эленеп тора (Над столом висит картина).*<br>*Син баладан көлмә (Ты не смейся над ребенком).* |
| под | астында | *Сумкаң өстәл астында аунап ята (Твоя сумка валяется под столом).* |
| около | янында<br>кырыенда | *Өстәл янында урындыклар тора (Около стола стоят стулья).*<br>*Өстәл кырыенда үзеңне матур тот (Около стола веди себя красиво).* |
| за | артында | *Шкаф артында өстәл тора (За шкафом стоит* |

| | | |
|---|---|---|
| | -га, -гә, -ка, -кә | *стол).*<br>*Мин кибет-кә ипигә кердем (Я зашел в магазин за хлебом).* |
| перед | алдында | *Шкаф алдында өстәл тора (Перед шкафом стоит стол).* |
| от | -дан, -дән, -тан, -тән, -нан, -нән | *Мин әнидән хат алдым (Я от мамы получил письмо).*<br>*Ул театрдан ерак яши (Он живнт далеко от театра).* |
| из | -дан, -дән, -тан, -тән, -нан, -нән | *Без театрдан чыктык (Мы вышли из театра). Укучылар автобустан төштеләр (Ученики вышли из автобуса).* |
| с | белән<br>-дан, -дән, -тан, -тән, -нан, -нән | *Мин театрга әни белән бардым (Я ходил в театр с мамой).*<br>*Мин сезнең белән танышырга телим (Я хочу с вами познакомиться).*<br>*Син бездән үрнәк ал (Ты бери пример с нас).*<br>*Сез ничәнче төркемнән? (Вы с какой группы?).* |
| до | кадәр (чаклы, хәтле) | *Мин театрга кадәр бардым (Я шел до театра).* |
| у | -ның, -нең<br>-да, -дә, -та, -тә | *Баланың уенчыгы бар (У ребенка есть игрушка). Минем уенчыгым балада (Моя игрушка у ребенка).* |
| для | өчен | *Бу безнең өчен бик мөһим (Это для нас очень важно).* |
| как | кебек, шикелле | *Безнең кебек эшлә (Работай как мы).* |
| через | аша, аркылы<br>-дан, -дән, -тан, -тән, -нан, -нән | *Күпер аша чыктым (Вышел через мост). Аның аркылы әйтеп җибәр (Передай через него). Син ничә сәгатьтән кайтасың? (Через сколько часов ты вернешься?).* |
| по | буйлап | *Мин коридор буйлап барап (Я иду по коридору). Елга буйлап кайттым (Приехал по реке).* |
| о, об | турында, хакында, хакта | *Синең турында уйлыйм (Думаю о тебе). Эш хакында сөйләштек (Говорили о работе).* |
| кроме | башка, тыш | *Синнән башка бу турыда беркем дә белми). Кроме тебя об этом никто не знает).* |
| к, ко | таба<br>-га, -гә, -ка, -кә | *Министерствога таба китте (Пошел к Министерству).*<br>*Имтиханга яхшы әзерләндегезме? (К экзамену хорошо подготовились?).* |

## ЗАДАНИЯ

***1. Переведите.***

Дустым белән сөйләшергә, балта белән чабарга, әдәбият белән кызыксынырга, спорт белән шөгыльләнергә, халык белән туларга, кызулык белән әйтергә, каты тавыш белән кычкырырга, үз юлы белән китәргә, таң белән уянырга, матур тавыш белән җырларга, эш өчен борчылырга, аның шикелле эшләргә, таш сыман каты, бриллиант алкасына кадәр бар, көзге кебек ялтырарга, Ватан өчен үләргә, кеше турында кайгыртырга, авыру сәбәпле эшкә килмәскә, дулкынга каршы йөзәргә, иртәдән бирле яңгыр ява, эштән соң туры өйгә кайтырга, синнән элек мин килдем, тау кадәр китап өеп куярга.

***2. Прочитайте текст, переведите. Вместо многоточий поставьте нужные послелоги.***

### Акча санаганны ярата

«Банк» дигән итальян сүзе безнеңчә «өстәл» төшенчәсен аңлата. Италиянең урта гасыр банкирлары үзләренең исәп-хисап эшләрен туп-туры базарда, өстәл янында башкара торган булганнар. Ә беренче банклар безнең эрага хәтле үк барлыкка килгәннәр. Моны борынгы Финикиядә, Карфагенда … Мисырда табылган папируслардагы язмалар раслый. Лондондагы Британия музеенда бер банкир йорты архивы саклана. Бу архивка 2700 ел.

Борынгы Грециядә дә банк исәп-хисапларын базар мәйданнарында, өстәл артында үтәгәннәр. Алар саклар өчен акча, сәүдә буенча килешү кәгазьләре … бүтән документларны кабул иткәннәр. Банкирлардан тыш, саррафлар (акча ваклаучылар) булган. Саррафлар төрле грек шәһәрләрендәге тәңкәләрне алыштырганнар (әлбәттә, процентлар исәбенә), аларны ялган түгелме икәнен ачыклаганнар. Алар төрлешәһәрләрдә булучы сәүдәгәрләрнең исәп-хисап эшләренә ярдәм иткәннәр.

Рим кешеләренең тырышлыгы белән бухгалтерия системасы камилләшкән.

Урта гасыр хакимияте … чиркәү банкирларга тискәре караштa була. Банкирларны христианнар йоласы буенча күмүне тыйганнар. 1240 елда Италиядән бөтен банкирларны да куалар, … 10 елдан кире кайтараоар. Банк системасы илләрне бер-бер артлы яулап ала.

1671 елда Шотландия шәһәре Эдинбургта Джон Ло дигән берәү дөньяга килә. 28 яшендә ул дуэльда катнашканы өчен үлем җәзасына хөкем ителә. … аның гаебен кичерәләр, үлем урынына төрмәгә генә утырталар. Ло төрмәдән Европага кача. Франциядә ул банк теориясе белән мавыга. Һәммә кешеләрне дә байларга әверелдерү турында ике китап бастыра. Моның өчен, ди Джон Ло, бөтен тәңкә акчаларны да кәгазь акчаларга алыштырырга … аларны теләсә нинди күләмдә бастырырга кирәк. Бу вакытта илдә Филипп Орлеанский

хакимлек итә, … аңа Джон Лоның идеясе ошый. Нәтиҗәдә, кәрт уенчысы Лоны банк директоры итеп сайлап куялар, аны академик исеменә лаек дип табалар, хәтта аңа финанс министры постын да тапшыралар.

*Сүзлек*

| | |
|---|---|
| төшенчә | понятие |
| туп-туры | прямо |
| үтә-ү | выполнять |
| саклар өчен | для хранения |
| килешү кәгазе | договор |
| ваклаучы | разменivатели |
| ялган | фальшивый |
| камилләш-ү | совершенствоваться |
| тискәре караш | отрицательное отношение |
| йола | традиция |
| күм-ү | хоронить |
| ты(й-у)ю | запрещать |
| ку-у | изгонять |
| берәү | некто |
| үлем җәзасы | смертная казнь |
| хөкем ит-ел-ү | быть приговоренным |
| гаеп | вина |
| кичер-ү | прощать |
| төрмә | тюрьма |
| кач-у | убежать |
| әверел-дер-ү | превратить |
| алыш-тыр-у | поменять |
| теләсә нинди күләмдә | в любом количестве |
| хакимлек ит-ү | управлять |
| кәрт уенчысы | картежник |
| сайла-п ку(й-у)ю | выбрать |
| лаек та(п)б-у | найти достойным |
| тапшыр-у | передать |

## 12. Килешүләр, банклар һәм кредитлар – Контракты, банки и кредиты

| | |
|---|---|
| • ***Деньги. Банк*** | • ***Деньги. Банк*** |
| • банкнот | • банкнот |
| • валюта | • валюта |
| • АКШ долларлары | • доллары США |
| • евро | • евро |
| • немец маркалары | • немецкие марки |
| • Швейцария франклары | • швейцарские франки |
| • Австрия шиллинглары | • австрийские шиллинги |
| • инглиз стерлинглары | • английские стерлинги |
| • евро курсы | • курс евро |
| • доллар курсы | • курс доллара |
| • вак акча | • мелочь |
| • акча ваклау | • разменивать деньги |
| • касса | • касса |
| • тәрәзә | • окошко |
| • кассир | • кассир |
| • хисап | • счет |
| • хисап ясау | • оплатить счет |
| • валюта алыштыру | • обменять валюту |
| • Якындагы банк кайда? | • Где находится ближайший банк? |
| • АКШ долларларын кайда алыштырырга мөмкин? | • Где можно обменять доллоры США? |
| • Хәзер евроның курсы нинди? | • Сейчас какой курс евро? |
| • Евроның курсы … | • Курс евро составляет … |
| • Минем исемемә акча күчерелгән. | • На мое имя поступил денежный перевод. |
| ***Банклар һәм кредитлар*** | ***Банки и кредиты*** |
| • түләү | • платеж |
| • базар | • рынок |
| • банк операцияләре | • банковские операции |
| • банкка акча салу | • вложить деньги в банк |
| • бурыч | • долг |
| • бурыч түләү | • оплатить долг |
| • килешү | • договор |
| • конрактка кул кую | • подписать контракт |
| • кредит шартлары | • условия кредита |
| • кулдагы акча | • наличные деньги |
| • процентлар | • проценты |
| • процентлар исәбенә | • за счет процентов |
| • сөйләшүләр | • переговоры |
| • сөйләшүләр алып бару | • вести переговоры |
| • сроклы хисап | • срочный счет |

- сроксыз хисап — бессрочный счет
- табыш — прибыль
- ташлама — льгота
- хисап — счет
- хисап ачу — открыть счет
- шарт — условие
- Без сроклы (сроксыз) хисап ачарга телибез. — Мы хотим открыть срочный (бессрочный) счет.
- Без үзебезнең … номерлы хисапка акча салырга телибез. — Мы хотим положить деньги на наш счет №…
- Без … номерлы хисптан акча алырга телибез. — Мы хотим взять деньги с нашего счета№…
- Бу банктагы салымнарның проценты күпме? — Каковы проценты по вкладам в этом банке?
- Кредитлар нинди шартларда бирелә? — На каких условиях предоставляется кредит?
- Без … кредит алырга телибез. — Мы хотим взять…. кредит.
  - озын сроклы — долгосрочный
  - кыскы сроклы — краткосрочный
- Кредит ун ел эчендә түләнергә тиеш. — Кредит должен быть погашен в течении десяти лет.
- Ставка процентларының күләме күпме? — Каков размер процентной ставки?
- Кредит елына … процент өстәмә түләү шарты бедән бирелә. — Кредит предоставляется под … процентов годовых.

## Союзы (Теркәгечләр)

Союзы служат для офомления связи между словами в предложении и частями сложного предложения.

| Теркәгечләр | Союзы | Примеры употребления |
|---|---|---|
| һәм | и | Әти һәм әни (Папа и мама). Мин эшлим һәм укыйм (Я работаю и учусь). |
| да, дә, та, тә | и, ни | Әти дә, әни дә (И папа, и мама). Мин эшлим дә, укыйм да (Я и работаю, и учусь). Ул эштә дә, өйдә дә юк (Его нет ни на работе, ни дома). |
| да, дә, та, тә | хотя, несмотря на | Син чакырмасаң да, мин килдем (Хотя ты и не пригласил, я пришел). Ул безгә бернәрсә әйтмәсә дә без беләбез (Мы знаем все, хотя он нам ничего не сказал). |
| ләкин | но | Ишеттем, ләкин аңламадым (Услышал, но не понял). Матур, ләкин тупас (Красивый, но |

| | | |
|---|---|---|
| | | грубый). |
| әмма | однако | Мин вакытында килдем, әмма ул киткән иде (Я пришел вовремя, однако он уже ушел). |
| ә | а | Ак түгел, ә сары (Не белый, а желтый). Мин түгел, ә син (Не я, а ты). Мин беләм, ә син белмисең (Я знаю, а ты не знаешь). |
| тик | только | Ул аңлый, тик сөйли генә белми (Он понимает, только не может говорить). Ул белемле, тик тәҗрибәсе аз (Он образованный, только опыта мало). |
| бары | только | Мине каршы алырга бары әти килгән (Меня встречать приехал только отец). |
| я, яки, яисә | или | Я мин, я ул (Или он, или я). Я эшлибез, я укыйбыз (Или работаем, или учимся). Я төзибез, я ватабыз (Или строим, или разрушаем). |
| әгәр | если | Әгәр син булмасаң (Если б не было тебя). Әгәр яңгар яуса, без урамга чыкмыйбыз (Если пойдет дождь, мы не выйдем на улицу). |
| чөнки | потому что | Мин килдем, чөнки сагындым (Я пришел, потому что соскучился). Алар бармадылар, чөнки вакытлары булмады (Они не поехали, потому что не было времени). |
| гүя, әйтерсең, диярсең | как будто, словно | Көн шундый аяз, җылы, гүя яз җиткән (День такой солнечный, теплый, как будто весна наступила. Ул өенә очып кайтты, әйтерсең аңа канатлар чыккан (Он прибежал домой так быстро, словно у него выросли крылья). Бу бала шундый акыллы, институт бетереп туган диярсең (Этот ребенок такой умный, как будто родился уже закончив институт). |
| гәрчә | несмотря на, хотя | Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем (Г. Тукай) (Хотя там и не родился, я немного там пожил). |
| ягъни | то есть | Иртәгә, ягъни җомга көнне, җыелыш булачак (Завтра, то есть в пятницу, будет собрание). |

| | | |
|---|---|---|
| аеруча, бигрәк тә | собенно | Аеруча язны яратам (Особенно люблю весну). Бигрәк тә сезне көтәбез (Особенно вас ждем). |

ЗАДАНИЯ

***1. Переведите.***

Керем һәм чыгым. Җитештерүче һәм кулланучы. Сатучы да, сатып алучы да. Ул сөйләшә һәм документларга кул куя. Марат әйтә дә язып куя. Укыдым, ләкин аңламадым. Вакытында килдем, ләкин ул әллә кайчан киткән иде. Ул яхшы белә, ә сиңа тырышыргы кирәк. Барысы да килгән, тик Роза гына юк. Я килермен, я шалтыратырмын. Син я үзең эшлә, я кешегә эшләттер. Ни трамвай, ни автобус юк. Әгәр яңгыр яуса — бармыйбыз. Мин вакытында эшне бетерә алмадым, чөнки авырдым. Әтисе, ягъни Әхмәт ул елларда сугышта булган. Кызлар, бигрәк тә Рәсимә белән Лена, бик шатландылар. Ул өенә очып кайтты, әйтерсең аңа канатлар чыккан.

***2. Прочитайте текст. Переведите.***

Совет чорында халык кредит хакында кинолардан гына ишетеп белә иде. Бу бары тик чит илләргә генә хас, ә безнең өчен ят күренеш кебек. Ләкин акрынлап әлеге көн безгә дә килеп җитте. Бүген Россиядә кредит белән бәйле булмаган кешене очрату кыен. Халык әҗәткә яшәүгә ияләшеп бара. Кесә телефоныннан башлап, машина һәм фатирлар кредитка алына.

*Сүзлек*

| | |
|---|---|
| чит илләргә хас | характерно для зарубежных стран |
| ят күренеш | не свойственное явление |
| акрынлап | постепенно |
| бәйле бул-у | быть связанным |
| очрат-у | встретить |
| әҗәт | долг |
| ияләш-ү | привыкать |
| кесә телефоны | мобильный телефон |

## Использованная литература

1) Газеев А.А. Изучаем татарский: это быстро и интересно. — Казань: Магариф, 1998. – 147 с.

2) Газизова Ф. М. Русско-татарский словарь экономических терминов. – Казань: Раннур, 1999. – 448 с.

3) Гыйләҗетдинова А. Татар телен өйрәнүчеләр өчен текстлар. – Казан: Иман, 1999. – 37 б.

4) Максимов Н.В. Технология обучения татарскому языку на основе моделей речи (на русском и татарском языках). – Казань: Татарское книжное изд-во, 2015. – 255 с.

5) Нигматуллина Р.Р. Сборник правил и упражнений для изучающих татарский язык. Морфология. В 2-х частях. — Н. Челны, 2004. — Часть 1 – 84 с., Часть 1 – 40 с.

6) Николаева М.М. Основы татарской грамматики. – Казань: Школа, 2003. – 80 с.

7) Николаева М.М. Сборник устных тем. - Казань: Школа, 2003. - 52 с.

8) Рахман Р. Дәреслектәге темалар һәм биремнәр буенча сочинениеләр. - Казан: Раннур, 2004. - 208 с.

9) Русско-татарский словарь: в 2-х томах. – Т. I (А - Л). – Казань: Магариф, 2007. – 726 с.; Т. II (М - Я) – 728 с.

10) Татарско-русский словарь. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1988. – 463 с.

11) Татар грамматикасы. – Т. II. – М.: Изд-во «Инсан», Казань: Изд-во «Фикер», 2002. – 448 с.

12) Нурмухаметова Р.С. Сборник правил по татарскому языку. – Казань: Издательство «Гыйлем», 2007. – 64 с.

13) Фаттахова Р.Ф. Введение в деловой татарский язык. - Казань: Школа, 2004. – 96 с.

14) Фаттахова Р.Ф. Практический татарский язык. Методическое пособие для изучающих татарский язык. - Казань: Тат.кн.изд-во, 2008. -167 с.

15) Фатхуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмухаметова Э.Н. Давайте говорить по-татарски/ Учебное пособие для студентов вузов. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2012. – 311 с.

16) Шаяхметова Л.Х. Татарский язык для начинающих: интенсивный курс. – Казань: Издательство: Татарское книжное издательство, 2012. 224 с.

**Приложение**

## Тексты для чтения и перевода

### Габдулла Тукай
### Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Хода

### Казан дәүләт аграр университеты тарихы

Казан дәүләт аграр университеты – бай тарихи традицияле Идел буе һәм Рәсәйдәге иң борынгы уку йортларының берсе. Казандагы авыл хуҗалыгы мәгарифенең чишмә башы Н.И. Лобачевский, А.М. Бутлеров, Н.П. Вагнер, М.Я. Киттара, Н.Я. Гордягин, И.В. Тюрин, В.П. Мосолов, И.В. Утей, Б.И. Горизонтов һ.б.ш. атаклы рус галимнәреннән үк башлана. Территориясе ягыннан бик зур һәм авыл хуҗалыгы ягыннан мөһим саналган Идел буе регионында бер генә дә югары авыл хуҗалыгы белеме бирүче уку йорты булмаган. Шуңа күрә дә Н.И. Лобачевский, Е.С. Фальков, А.Н. Остряков, Ф.Т. Дяткин кебек җәмгыятьнең алдынгы эшлеклеләре, профессорлар тарафыннан борынгы культура һәм фән үзәге булган Казанда югары авыл хуҗалыгы мәктәбен ачу турында мәсьәлә куелган. 1918 нче елның 25 нче ноябрендә Мәскәүдә югары уку йортлар бүлеге коллегиясенең утырышында Казан университеты каршында урман факультетына нигез салу турында карар кабул ителгән. Урман факультетының беренче деканы профессор А.А. Юницкий була. 1922 нче елның 22 нче маенда университетның урман факультетын һәм политехник институтының авыл хуҗалыгы факультетын бергә кушып, авыл хуҗалыгы һәм урман бүлекләреннән мөстәкыйль Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институтын булдыру турында РСФСР Главпрофобрның карары басылып чыга.

Яңа аграр вузның башында шул заманның данлыклы галимнәре тора. Институтның беренче ректоры проф. Н.Н. Парфентьев 1911 нче елда югары математика магистры исемен ала, ә 1912 нче елда Лобачевский исемендәге алтын медальгә лаек була. РСФСРның халык мәгарифе комиссары А.В. Луначарскийга ул болай дип яза: “Институтта гомуми белем бирү бик әйбәт куелган, чөнки институтта борынгы Казан университетының физика-математика факультетының бөтен коллективы да диярлек эшли...” Бу чыннан да шулай була. Мәсәлән, авыл хуҗалыгы бүлегендә аналитик химияне проф. А.М. Васильев, ботаника һәм үсемлекләр систематикасын проф. А.Я. Гордягин, югары математика һәм механиканы проф. Н.Н. Парфентьев, геодезияне – проф. М.А. Грачев, геологияне – проф. М.Э. Ноинский, зоологияне – проф. Н.А. Ливанов, болынчылык һәм сазлык белемен – проф. В.П. Ищеряков,

микробиология һәм фитопатологияне – проф. А.П. Пономарев, минералогияне – проф. Б.П. Кротов, органик булмаган химияне – проф. А.Я. Богородский, гомуми һәм хосусый терлекчелекне – проф. В.Г. Беляев, җир белемен – проф. Ф.В. Чириков, авыл хуҗалыгы машиналары белемен – проф. Б.И. Горизонтов, авыл хуҗалыгы икътисады һәм статистикасы, авыл хуҗалыгын һәм исәп-хисап эшен оештыруны – проф. Ф.Т. Дитякин, физика һәм метерологияне – проф. В.А. Ульянин, хайваннар физиологиясен – проф. А.Ф. Самойлов һ.б. укытканнар.

1924 нче елда проф. С.П. Вострокнутов тарафыннан авыл хуҗалыгын механикалаштыру кафедрасы ачыла. Монда ул “Авыл хуҗалыгы машина белеме” курсын укый. Соңрак нәкъ шушы кафедра базасында механикалаштыру факультеты оеша.

1925 нче елда селекция һәм орлыкчылык кафедрасы оеша. Аны РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор П.М. Тихонов җитәкли.

1926 нчы елның маенда институт бүлекләре:

а) үсемлекчелек, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгын оештыру секцияләре белән авыл хуҗалыгы факультетына;

б) урман факультетына әйләнә.

1926 нчы елда урман факультетының чыгарылыш студентлары арасында киләчәктә галим, химик-органик, СССР ФА академигы, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Б.А. Арбузов “Опыт применения химических методов и определению смол и скипидаров из Pinus silvetris” темасына диплом эше язып яклый.

1927 нче елның җәендә безнең институтның авыл хуҗалыгын механикалаштыру кафедрасы каршында машина сынау станциясе булдырыла. Бу станция безнең илебез генә түгел, шулай ук чит илнең күп кенә заводлары машиналарына сынау үткәрә. Шунысы кызыклы: 1927 нче елда проф. С.П. Вострокнутов – авыл хуҗалыгы машиналары кафедрасына нигез салучы – Германиядә стажировка үтә, авыл хуҗалыгы машиналары төзү заводларында була һәм Рейн – Металл фирмасының печән чабу җайланмасы белән бүләкләнә. Агрономия факультетының II һәм III курс студентлары ярдәмендә һәм ассистент Г.Ф. Захарченко белән берлектә Ферма 2 нче территориясендә авыл хуҗалыгы машиналарын йөртү һәм сынап карау өчен уку полигоны ясый.

Шушы полигон базасында 1929 нчы елда Татарстанда беренче машина сынау станциясе оеша. Машиналарны сынап карауда Коновалов И.Д., Антонов Н.В., Афанасьев С.К., Важинский А.В. кебек студентлар катнаша. Соңрак алар авыл хуҗалыгы машиналары кафедрасында укытучы булалар.

1927 нче елның 11 нче октябрендә интситутка татар яшьләренә “яшел ут” ачкан төрки-татар рабфагы кушыла. Шуңа бәйле рәвештә 1927 нче елдан алып 1929 нче елның январенә кадәр татар студентларының саны 4,6 дан 11,4 % ка арта. Бу – 2,5 тапкырга үскән дигән сүз.

1929 нчы елдан алып институтның хезмәткәрләре һәм студентлары авыл хуҗалыгын коллективлаштыру эшенә керешәләр. Алар әйтүенчә, бу уңыш өчен көрәш була. Бу эштә активлардан декан В.П. Мосолов җитәкчелегендәге

агрономия факультеты санала. Шул ук елны институтта трактор сатып алу өчен акча җыю игълан ителә. “Тимер атны” тантаналы рәвештә “Алга” колхозына бирәләр.

1930 нчы елда институт 2 вузга бүленә: урман-техник (Йошкар-Ола шәһәре) һәм авыл хуҗалыгы институты (Казан шәһәре). Шулай итеп, 1930 нчы елда институт составына бары тик бер генә – агрономия факультеты гына керә. 1933 нче елның көзендә Казан авыл хуҗалыгы институтына зоотехника факультеты дип үзгәртеп сөт хуҗалыгы институты кушыла. Соңрак бу факультет Казан ветеринар институтына бирелә. Бөек Ватан сугышы елларында институт коллективы Ватанны саклау юлына баса. 1941 нче елда 52 студент һәм ректор Анисимов җитәкчелегендә укытучылар фронтка китә. Сугышның авыр елларында да институт югары квалификацияле белгечләр әзерләүне дәвам итә. Сугыш елларында институт ректорлары булып А.К. Вершинин һәм В.К. Голосов эшли. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда җиләк-җимеш – яшелчә (1943–1948), агроурманмелиорация факультетларында (1949–1955) студентлар әзерләү эше алып барыла. Сугыштан соңгы елларда КДАХИ ректоры булып С.Н. Коньков эшли. 1950 нче елда авыл хуҗалыгын механикалаштыру дигән яңа факультет ачыла. Декан итеп И.В. Коновалов сайлана. 1961 нче елда икътисад факультеты ачыла. Деканы С.И. Кагункин була. Озак еллар дәвамында (1965–1992) җитәкче кадрлар авыл хуҗалыгы белгечләренең квалификациясен күтәрү факультеты эшләп килә (Проректор Г.Ф. Мамаков).

Мәгариф һәм авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыклары карары нигезендә 1995 нче елда Казан авыл хуҗалыгы институтына авыл хуҗалыгы өлкәсендә эре уку-фәнни үзәк буларак академия статусы бирелде. 1996 нчы елдан академия, хәзер университет белән Җ.И. Фәйзрахманов җитәкчелек итә.

2006 нчы елның 27 августында академия “Казан дәүләт аграр университеты” дигән яңа статус алды.

Авыл хуҗалыгы фәнен үстерүдә университет галимнәренең һәм студентларының өлешләре зур һәм күпкырлы. Университетның фәнни казанышлары ТР да гына түгел, Россия Федерациясендә дә практик яктан кулланылышта.

Университетның престижы югары. Аны тәмамлаган студентлар абруй казаналар һәм туган вузыбызның данын арттыралар.

www.kazgau.ru сайтыннан алынды

**Фәйзрахманов Җәүдәт Ибраһим улы - Казан дәүләт аграр университеты ректоры**

Фәйзрахманов Җәүдүт Ибраһим улы 1948 нче елның 27 нче июнендә Татарстан Республикасы Арча районы Носы авылында күп балалы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Үзенең хезмәт эшчәнлеген 1966 нчы елда ул, Казан авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, ТР Арча районы “Первое мая” колхозында экономист булып башлап җибәрә. 1972 нче елда Казан авыл хуҗалыгы институтының икътисад факультетын тәмамлый. 1973 нче елдан профессор Н.С. Катков җитәкчелегендә КСХИ да аспирантура үтә, аспирантурада укыганда Совет Армиясе хезмәтенә (1974–1975) алына. 1978 нче

елны “Вопросы организации и планирования рациональной кормовой базы в хозяйствах с развитым молочным скотоводством” темасын кандидатлык диссертациясен уңышлы гына яклый. 1991 нче елда К.А. Тимирязев исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясендә терлекчелек һәм азык җитештерүдә экономик яктан эффектлылыкны күтәрү проблемаларын яктырткан докторлык диссертациясен яклый (08.00.05 белгечлеге – икътисад, планлаштыру һәм халык хуҗалыгы белән идарә итүнен оештыру (авыл хуҗалыгы).

1977–1990 нчы елларда КСХИның экономик кибернетика кафедрасында ассистент, өлкән укытучы, доцент, мөдир вазифаларын башкаручы булып эшли. 1990–1996 нчы елларда ул – Казан дәүләт ветеринар академиядә авыл хуҗалыгы экономикасы һәм ветеринар эшен оештыру кафедрасы доценты, авыл хуҗалыгында икътисад һәм маркетинг кафедрасы мөдире. Ул – көчле, оештыру сәләтләре югары булган җитәкче, коллектив хөрмәтен казанган шәхес. 1992 нче елны аңа икътисад һәм маркетинг кафедрасы профессоры исеме бирелә. 1996 нчы елдан алып бүгенге көнгәчә Җ.И. Фәйзрахманов КДАУның авыл хуҗалыгында җитештерү белән идарә итү кафедрасын җитәкли.

Фәйзрахманов Җ.И. терлекчелек һәм азык җитештерүдә экономик яктан эффектлылыкны күтәрү проблемаларын өйрәнү, компьютер технологияләрен булдыру һәм аны гамәлгә кертү, шулай ук АПК аграр секторын реформалаштыру өлкәләрендә атаклы галим буларак танылды. Фәнни нәтиҗәләрне реализацияләү ТР АПКсының стабиль үсешен тәэмин итүдәге уңай роле бәяләп бетермәслек.

Фәйзрахманов Җ.И. – АПК реформалауның актуаль мәсьәләләре һәм аграр сеторның экономик яктан эффектлылыгын күтәрүгә багышланган 15 монография һәм 100 фәнни хезмәт авторы. 2000 нче елда ул ТР ның иң яхшы инновацион идеясе өчен Диплом белән бүләкләнде.

Фәйзрахманов Җ.И. югары авыл хуҗалыгы белеме бирү үсешенә, бу тармакның фәнни яктан тәэмин ителешенә, фәнни-педагогик кадрлар әзерләүгә үзенең зур шәхси өлешен кертте. Ул үзенең фәнни юнәлешләренә нигезләнеп фәнни мәктәп оештырды, 15 кандидат һәм 5 икътисад фәннәре докторы әзерләде.

Фәйзрахманов Җ.И. актив фәнни-оештыру эше алып бара: ул – ТР ФА-ң экономик проблемаларны реформалау буенча Гыйльми совет рәисе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт премияләре бирү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссиянең әгъзасы, “Вестник Казанского ГАУ” журналының баш мөхәррире, “Нива Татарстана” журналының редколлегия әгъзасы, докторлык диссертация советының әгъзасы.

1996 нчы елның августында Фәйзрахманов Җ.И. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең ректоры итеп сайлана. Ректор булып эшләү дәверендә ул үзен көчле оештыручы, талантлы педагог һәм фәнни җитәкче буларак күрсәтте. 2002 нче елда ул “Мәгариф сферасы” номинациясендә “Елның иң яхшы менеджеры” исеменә лаек була. 2005 нче елда “Ел ректоры” номинациясендә Милли премия лауреаты була. Ул җитәкчелек иткән еллар – вузның динамик үсеш, белем бирү эшчәнлеге сферасының киңәю, фәнни

потенциалы үсеше һәм матди-техник базаның ныгу еллары. Фәйзрахманов Җ.И. җитәкләгән бөтен коллектив эшенең нәтиҗәләре, динамик һәм стабиль үсеш, 2006 нчы елда вузга югары статус – университет статусын бирде.

Җ.И. Фәйзрахмановның эшләгән эшләре, кылган гамәлләре аны ТР ФА-ң әгъза-корреспонденты, Югары мәктәпнең Халыкара фәннәр академиясе әгъзасы һәм аграр белем бирүнең Россия академиясе әгъза-корреспонденты итеп сайланырга җирлек бирде.

Хезмәт эшчәнлеге дәверендә ул "Бөтенроссия халык санын исәпкә алуны үткәрүдәге казанышлары", "Казанның 1000 еллыгы истәлеге", "Хезмәт ветераны" медальләре, РФ Президентының мактаулы грамоталары белән бүләкләнде.

www.kazgau.ru сайтыннан алынды

## Татарстан Республикасының беренче Президенты М.Ш.Шәймиев

Минтимер Шәрип улы Шәймиев 1937 елның 20 гыйнварында хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында крестьян гаиләсендә туа. М.Ш.Шәймиевнең бабасы - Шәймөхәммәт урта хәлле, таза тормышлы игенче булган. Коллективлаштыру елларында, кулак дип санап, аны йортыннан, мал-туарларыннан мәхрүм иткәннәр. Минтимер Шәриповичның атасы - Шәһишәрип ага Шәймиев бөтен гомере буена авыл хуҗалыгында эшли (26 ел дәвамында колхоз рәисе булып тора).

1954 елда М.Ш.Шәймиев мәктәпне тәмамлый һәм Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Казан авыл хуҗалыгы институтының механикалаштыру факультетын тәмамлаганнан соң (1959 ел) авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсендә эшли.

1969-1983 елларда - ТАССРның мелиорация һәм су хуҗалыгы министры.

1983 елда ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары.

1983-1985 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре.

1985-1989 елларда - ТАССР Министрлар Советы Рәисе.

1989-1990 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре.

1990 елда ТАССР Югары Совет Рәисе итеп сайлана. Шул елда Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителә.

1991 елның 12 июнендә Татарстан Республикасының беренче Президенты итеп сайлана. Татарстанның күпмилләтле халкы республикада тынычлык һәм иминлекне ныгыту, катлаулы социаль-икътисадый проблемаларны хәл итү буенча М.Ш.Шәймиев тырышлыгына югары бәя бирә. Ике мәртәбә (1996 елның 24 мартында һәм 2001 елның 25 мартында) ул яңадан Татарстан Республикасы Президенты итеп сайлана.

1994-2001 елларда Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы әгъзасы.

2005 елның 25 мартында Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин күрсәтүе буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан М.Ш.Шәймиевкә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре бирелә.

2001 елның 1 декабреннән "Бердәм Россия" партиясенең Югары Советы рәистәше.

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевның вәкаләтләр чоры 2010 елның 25 мартында бетте.

2010 елның 21 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе итеп билгеләп куелды.

## XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада

2008 елның 31 маенда Брюссельдә Казанның 2013 елгы җәйге Универсиаданы үткәрү хокукын яулавы игълан ителә. Халыкара студентлар спорты федерациясе (FISU) башкарма комитетының 27 әгъзасыннан 20 есе Казан өчен тавыш бирә.

2013 елда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада бүгенге Россия тарихында беренче Универсиада, алай гына да түгел, беренче мульти-спорт чарасы булачак. Универсиада 2013 елның 6 – 17 июль көннәрендә үтәчәк.

2013 елда Казанда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада миссиясе күпмиллэтле кабатланмас мирасы булган шәһәрдә дөньяның төрле почмакларыннан килгән яшь спортчыларны җыю. Россиядәге спорт традицияләрен дәвам итү, яшь буын спортчылар өчен яңа уңышларга ирешү өчен этәргеч ясау. Казанлыларның тормышын төрлерәк, кызыклырак, җайлырак итү. Безгә һәм балаларыбызга яраткан спорт төрләре белән шөгыльләнү, сәламәт тормыш алып бару өчен шартлар тудыру. Россиянең дөньякүләм дәрәҗәсен арттыруга лаеклы өлеш кертү. 2013 елда Казанда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада символикасы



Универсиада символикасы логотип, эмблема һәм талисманнан гыйбарәт.

Универсиада логотибында латин алфавитындагы U хәрефе язылышына охшаш элементлар булырга тиеш. Бу – Халыкара студентлар спорты федерациясе үткәргән бөтен чараларның символикасында мәҗбүри булырга тиешле элемент. 2013 елгы Универсиада логотибы вертикаль буенча сузылган дүртпочмак формасында эшләнгән. Әлеге дүртпочмакны инглиз телендә язылган Универсиада, Казан, Универсиаданы үткәрү елы, Россия һәм Халыкара студентлар спорты федерациясенең биш йолдызы формалаштыра.

Универсиада эмблемасы латин алфавитындагы U хәрефе һәм 5 континенты символлаштыручы төрле төстәге йолдызлардан тора. Шулай ук Универсиада эмблемасы Бөтендөнья студентлар уеннарының ак әләмендә дә

бар. 2013 елгы Универсиада эмблемасы нигезендә – традицион татар орнаменты элементы булган лалә чәчәге. Чәчәк ул – җәй атрибуты, яшьлек һәм үсеш, бәхет-шатлык символы.

Бүген мәгънәви эчтәлеге шактый баеган милли орнамент халык иҗатында мөһим роль уйнвауын дәвам итә.

Казан Универсиадасының Талисманы – Юни (Uni) кушаматлы канатлы ак барс малае. Канатлы ак барс – Татарстан Республикасының милли символы. Ул Татарстанның гербында да урын алган.

U are the World

**Бөтендөнья Универсиадалары шигаре**

Олимпия уеннарының 1894 елда Пьер де Кубертен тәкъдим иткән «Citius, Altius, Fortius» («Тизрәк, Югарырак, Көчлерәк») шигареннән аермалы буларак, Студентларның халыкара уеннарының даими шигаре юк. Универсиаданы оештыручылар үз вариантын тәкъдим итә, FISU аны раслый. 2013 елгы Универсиаданың шигаре – «U are the world». Әлеге шигарьне ике төрле аңлатырга мөмкин: «Син – ул дөнья» һәм «Универсиада – үзе бер дөнья».

**Бөтендөнья универсиадалары гимны**

1959 елда Туринда узган Студентларның беренче Бөтендөнья җәйге уеннарында җиңүчеләр хөрмәтенә студентлар гимнын – «Гаудемаус»ны яңгырату кабул ителә. Гимнга көйне XV гасырда ук Иоганн Океңгейм иҗат итә, тексты исә XVIII гасыр ахырында гына формалашып бетә. Студентларның халыкара уеннарын үткәрү дәверендә «Гаудемаус» FISU эмблемасы яисә уеннарның талисманы сыман ук, Универсиада символына әйләнә.

kazan2013.ru сайтыннан алынды

**Казан метрополитены**

Казан метрополитены – заманча, популяр һәм үтемле транспорт төре. Метро шулай ук бик уңайлы һәм тиз йөрешле җәмәгать транспорты. Россиядә ул иң куркынычсыз транспорт төре, дип санала.

Казан метросының беренче линиясе 10,32 чакрым озынлыкта. Линиядә 7 станция урнашкан: «Җиңү Проспекты», «Таулар», «Әмәт», «Сукно бистәсе», «Тукай мәйданы», «Кремль» и «Кәҗә бистәсе». Тагын өч станциядә төзелеш эшләре бара. Алар Универсиадага кадәр кулланылышка тапшырылырга тиеш.

Метро төзү – шәһәрдәге транспорт челтәрен үстерүнең тагын бер чарасы. Ул шәһәрнең төрле почмакларын бәйләп тора, Казансу елганың ике ярын тоташтыра, бер зур микрорайоннан тиз арада икенчесенә барып җитү мөмкинлеге бирә. Метрополитен Универсиаданың 30 спорт корылмасын үзара тоташтыра. Әлеге спорт корылмалары арасында Казанның иң эре спорт мәйданнары да бар. Казан метросы инде бүген көненә 220 мең пассажирга хезмәт күрсәтә.

intertat.ru сайтыннан алынды